КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 апрель г.Казань № 520

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 июнь, 481 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 16 август, 839 нчы, 2023 ел, 24 гыйнвар, 37 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, 9 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия

юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы җыелма командасының (вәкилләренең) төрле дәрәҗәдәге һөнәри осталык чемпионатларында һәм мәгариф һәм фән өлкәсендәге башка конкурсларда катнашуын оештырып, мәгариф һәм фән өлкәсендә чараларны (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук башка чаралар) оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 август, 689 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 23 август, 892 нче, 2022 ел, 29 декабрь, 1438 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы җыелма командасының (вәкилләренең) төрле дәрәҗәдәге һөнәри осталык чемпионатларында һәм мәгариф һәм фән өлкәсендәге башка конкурсларда катнашуын оештырып, мәгариф һәм фән өлкәсендә чараларны (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук башка чаралар) оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, 7 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик затлары (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2021 ел, 13 август, 708 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 15 ноябрь, 1078 нче; 2022 ел, 29 июнь, 613 нче, 2022 ел, 2 сентябрь, 956 нчы, 2023 ел, 3 февраль, 92 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» гранты турындагы нигезләмәгә, 10 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процентtan арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциячел булмаган оешмаларга сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау, аларга ярдәм итү һәм аларны озатып бару чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 23 август, 771 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 июль, 729 нчы, 2022 ел, 29 декабрь, 1448 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Коммерциячел булмаган оешмаларга сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау, аларга ярдәм итү һәм аларны озатып бару чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, 9 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процентtan арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;».

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче программалар – бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча Кытай Халык Республикасыннан татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 28 октябрь, 1007 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 12 август, 803 нче, 2022 ел, 29 декабрь, 1444 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүче программалар – бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары, аспирантурада (адъюнктурада) фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча Кытай Халык Республикасыннан татар диаспорасы вәкилләрен укытуга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, 6 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;».

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү, шәхси гомуми белем бирү оешмалары һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 10 октябрь, 1060 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 10 август, 785 нче, 2022 ел, 29 декабрь, 1438 нче карарлары белән кертелгән

үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү, шәхси гомуми белем бирү оешмалары һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, 10 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;».

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасыннан катнашучыларны төрле дәрәҗәдәге «Ворлдскиллс» стандартлары буенча чемпионатларга әзерләү өлешендә устав эшчәнлеген, «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә чараларны оештыруны финанс белән тәэмин итүгә коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 2 август, 747 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 декабрь, 1438 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасыннан катнашучыларны төрле дәрәҗәдәге «Ворлдскиллс» стандартлары буенча чемпионатларга әзерләү өлешендә устав эшчәнлеген, «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә чараларны оештыруны финанс белән тәэмин итүгә коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия

юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

8 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1 нче көненә коммерциягә карамаган оешманың офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры (яки) турыдан-туры булмаган (өченче зат аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын раслый торган, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан кул куелган гарантия хаты;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин